КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 4 июль г.Казань № 787

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карары белән расланган 2023 елда яшь кош-корт сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә шәхси ярдәмче хуҗалыкларны үстерүгә дәүләт ярдәме чаралары турында» 2021 ел, 15 июнь, 452 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 ел, 26 март, 275 нче; 2022 ел, 22 август, 884 нче; 2023 ел, 6 февраль, 106 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган 2023 елда яшь кош-корт сатып алу чыгымнарының бер өлешен каплау өчен шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 пунктның бишенче абзацында «01.47» саннарыннан соң «, 01.47.1» саннарын өстәргә, «әлеге продукцияне турыдан-туры җитештерүчеләре булып торган» сүзләрен төшереп калдырырга;

9 пунктның дүртенче абзацында татар текстында «касса чегы,» сүзләреннән соң «яки касса керем ордерларына квитанция,» сүзләрен өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин